**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О проведении татарского народного праздника «Сабантуй»**

В целях организованного проведения в 2017 году татарского народного праздника «Сабантуй» и на основании статьи 2 Закона Республики Татарстан от 19 февраля 1992 года № 1448-XII «О праздничных днях и памятных датах Республики Татарстан» **постановляю**:

1. С учетом предложений органов местного самоуправления провести татарский народный праздник «Сабантуй» в следующие сроки:

в сельских населенных пунктах, районных центрах Республики Татарстан (в том числе и в городах республиканского значения) – 1-2 июля 2017 года;

в городе Набережные Челны – 8 июля 2017 года;

в столице Республики Татарстан городе Казани – 15 июля 2017 года.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан совместно с органами местного самоуправления обеспечить организацию проведения праздничных мероприятий в указанные сроки.

3. Предложить органам местного самоуправления, общественным объединениям, предприятиям, организациям принять активное участие и оказать содействие в организации и проведении татарского народного праздника «Сабантуй» в определенные настоящим Указом сроки.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
24 марта 2017 года
№ УП-238

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында

2017 елда «Сабан туе» татар халык бәйрәмен оешкан төстә үткәрү максатында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге срокларда уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә дә) – 2017 елның 1-2 июлендә;

Чаллы шәһәрендә – 2017 елның 8 июлендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2017 елның 15 июлендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән срокларда уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән вакытларда оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга һәм булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2017 ел, 24 март
№ ПУ-238